| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ МОНАШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ МОНАШЕВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

10.10.2023 ел N 102

Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Советының
2020 елның 26 февралендәге 136 номерлы
“Җир салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының 2020 елның 26 февралендәге 136 номерлы “Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында
1.1. Карарның 2 пунктының 3 абзацында "һәм объектлар белән" сүзләрен “һәм (яисә) объектлар белән" сүзе белән алыштырырга, "объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуклы өлеш" сүзләрен "күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешләре" сүзләре белән алыштырырга, "һәм объектарга” сүзләрен "һәм (яисә) объектарга" сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында " Монашево авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән алып бер ай узгач, әмма тиешле салым (иминият взнослары) буенча чираттагы салым (хисап) чорының 1 нче көненнән дә иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Монашево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф.Иосифов